Республика Татарстан
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУРТЫШ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул. Советская, д. 47, с. Муртыш-Тамак
423358
Телефон: 4-52-05

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 47 йорт, Мортыштамак авылы,
423358
Телефон: 4- 52-05

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.02.2016 ел №10

Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге Советының «җир салымы турында»11.11.2014 ел, № 12 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 43.1 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлеклөрдән Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, муниципаль норматив хокукый актлар юнәлешләре һәм алар турында белешмәләрне 2014 елның 11 гыйнварыннан Сарман муниципаль районы башлыгы белән төзелгән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә карар итәм:

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башлыгының 2014 елның 11ноябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җыю һәм җибәрү буенча эш барышында Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләрне җыю һәм җибәрү буенча үзара эшчәнлек регламентына таянып эш итәргә.

2. Җирлек Советының, җирлек башлыгының һәм җирлек башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый актларын, шулай ук регистрга кертелергә тиешле белешмәләрен муниципаль район Советына юллаган өчен җирлек башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарын (секретарен) җаваплы итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасының «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н.Әхмәтгәрәев